СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район, п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 278 от 30.07.2024
на № _________от _____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2019 елның 23 октябрендәге 308 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет законнары үзгәрүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

**1.** «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2019 елның 23 октябрендәге 308 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 8 статьяның 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле егерме икенче абзац өстәргә:

« - «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интегральләшкән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи, аларга федераль бюджет акчалары (капиталь төзелеш объектларыннан һәм дәүләт оборона заказына кертелгән күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булып тора;».

**2.** 23 статьяның 3 пунктының, 26 статьяның 3 пунктының гамәлдә булуын 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**3.** Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә игълан итәргә.

Саба муниципаль районы
Башлыгы Р.Н. Минниханов